ГЛАВА
МАЛЬБАГУШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Нефтяников, д30, с.Мальбагуш,
Азнакаевский муниципальный район 423330

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ МӘЛБАГЫШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ БАШЛЫГЫ

Нефтьчеләр ур., 30 нче йорт, Мәлбагыш авылы,
Азнакай муниципаль районы, 423330

Тел./факс(885592)3-77-90,3-77-91; E-mail:Malb.Azn@tatar.ru,

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» октябрь 2022 ел № 5

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлегенең Мәлбагыш торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Уставы нигезендә, **карар итәм:**

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Мәлбагыш авылында Җәлил урамы 6 нче йорттан 62 йортка, Кооператив урамы 1нче йорттан 11 нчы йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2022 елның 23 октябрендә 9 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Мәлбагыш авылында Колхозчылар урамы 1 нче йорттан 16 нчы йортка, Комсомол урамы 1нче йорттан 57 нче йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2022 елның 23 октябрендә 11 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Мәлбагыш авылында Нефтьчеләр урамы 1 нче йорттан 60 нчы йортка, Мәллә урамы 1 нче йорттан 6 нче йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2022 елның 23 октябрендә 13 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының өченче этабын билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Мәлбагыш авылында Нариман урамы 1 нче йорттан 63 нчы йортка, Җәлил урамы 1нче йорттан 3 нче йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2022 елның 23 октябрендә 15 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының дүртенче этабын билгеләргә.

5.Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Мәлбагыш торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын

оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Башкарма комитеты;

- гражданнар җыенының беренче этабын уздыру вакыты – 23 октябрь 2022 ел 9.00 сәг.тән 10.00 сәг.кадәр;

- гражданнар җыенының икенче этабын уздыру вакыты – 23 октябрь 2022 ел 11.00 сәг.тән 12.00 сәг.кадәр;

- гражданнар җыенының өченче этабын уздыру вакыты – 23 октябрь 2022 ел 13.00 сәг.тән 14:00 сәг.кадәр;

- гражданнар җыенының дүртенче этабын уздыру вакыты – 23 октябрь 2022 ел 15.00 сәг.тән 16.00 сәг.кадәр;

- гражданнар җыенының беренче, икенче, өченче, дүртенче этапларын уздыру урыны – Мәлбагыш авылы, Җәлил ур. , 4 нче йорт, Мәлбагыш авыл Мәдәният йорты залы;

6. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2022 елның 11 октябреннән дә соңга калмыйча гражданнарга Мәлбагыш авылы, Нефтьчеләр урамы, 30 нчы йорт адресы буенча урнашкан, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Башкарма комитетында һәм Мәлбагыш авылы, Җәлил урамы, 4 нче йорт адресы буенча урнашкан (авыл мәдәният йорты) мәгълүмат стендында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын бирергә;

- Мәлбагыш торак пунктында сайлау хокукына ия булган яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Мәлбагыш торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнарның җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

7. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2023 елда 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, Мәлбагыш авыл җирлеге Мәлбагыш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Мәлбагыш авылында механикалаштырылган кар чистарту хезмәтләре өчен түләү (килешү буенча эшләр өчен түләү, механикалаштырылган кар чистарту буенча хезмәтләр күрсәтү , юлларны кардан чистарту буенча чит оешмаларга хезмәт күрсәтү, ягулык-майлау материаллары һәм трактор өчен запчастьләр алу

- җәйге чорда Мәлбагыш авылында үлән чабу, территорияне җыештыру буенча хезмәтләр (килешү буенча эшләр өчен түләү, триммер өчен запас частьләр сатып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

- Мәлбагыш авылында «Сабантуй», «Җиңү көне»” Өлкәннәр көне”, “Инвалидлар көне”, “Яңа ел” бәйрәмнәрен оештыру һәм үткәрү (бүләк, сувенир продукция сатып алу);

-күмелгән урыннарны карап тоту (дератизация, тоташ гербицид белән химик эшкәртү, агач кисү, куакларны кисү, үлән чабу, чүп-чар җыю, хуҗалык инвентаре, инструментлар һәм җиһазлар сатып алу, запас частьләр сатып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

- трактор өчен кар чистарткыч сатып алу;

« РИЗА» «КАРШЫ»

8. Әлеге карарны Мәлбагыш авылы, Нефтьчеләр урамы, 30 йорт адресы буенча урнашкан, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Башкарма комитетында һәм Мәлбагыш авылы, Җәлил урамы, 4 нче йорт адресы буенча урнашкан (авыл Мәдәният йорты) адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми

сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. урнаштырырга

9. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык А.Й.Әхмәтшин